ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 23.08.2023 **КАРАР**
1239

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урынынын яшәргә яраклы, яки яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә, сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 1548 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау һәм эшләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 февралендәге 166 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урынынын яшәргә яраклы, яки яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә, сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 1548 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2.4.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтелә:

гариза биргән көнне дә кертеп, 30 календарь көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә;

торакны тикшерү акты төзелгән очракта, 32 календарь көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә (4 нче кушымта);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарының 42 пунктында каралган, гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта объектларның (торак урыннарның) җыелма исемлегенә кертелмәгән торак урынның хуҗасы, милекченең гаризасы каралган очракта, 20 көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә.

Торак урын милекчесе, хокук иясе яки яллаучының гаризасы каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен теркәгән көнгә кадәр муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, ул гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта 47 номерлы карарның 42 пунктында каралган объектларның (торак урыннарның) җыелма исемлегенә кертелмәгән, гариза теркәлгән көннән алып 30 календарь көннән дә артык булмаган, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтү вакыты гариза теркәлгән көннән алып 20 календарь көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чykканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Л. Исланов